РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

с. Тюлячи

КАРАР

«20» сентября 2023г.

№ 148

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 14 июлендәге 137 номерлы «Яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 14 июлендәге 137 номерлы «Яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карар белән расланган Яшел утыртмаларны кисү хокукына рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына:

III бүлектә:

а) 3.1 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гарызнамәне формат - логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең һәрбер электрон форма гарызнамәсен тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Бердәм портал тарафыннан гарызнамәнең электрон рәвештә тутырылган кырының корректлы булмавы ачыкланса, мөрәҗәгать итүчегә турыдан-туры гарызнамәнең электрон формасында ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында мәгълүмати хәбәр ителә.»;

б) 3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак аны сайлау мөмкинлеге тәэмин ителә:

а) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып имзаланган электрон документ алу;

б) норматив хокукый актлар нигезендә мондый мәгълүмат көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән орган (оешма) ягыннан мәҗбүри

имзалауны таләп итә торган очраклардан тыш, дәүләт (муниципаль) мәгълүмат системаларыннан мәгълүмат алу;

в) гарызнамәдә булган һәм (яисә) гарызнамәгә кушымта итеп бирелүче документлардагы мәгълүмат нигезендә дәүләт (муниципаль) мәгълүмат системаларындагы белешмәләрне хезмәт күрсәтү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актларда каралган очракларда үзгәрешләр кертү;

г) органның (оешманың) тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган машина укыла торган форматта бердәм порталны кулланып электрон документ алу (алга таба - машина укыла торган форматта электрон документ).»;

в) 3.5 пунктны түбәндәге эчтәлекле 3.5(1) пунктча белән тулыландырырга:

«3.5(1). Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты тиешле бердәм портал, хезмәт күрсәтүләр порталы тарафыннан хезмәт күрсәтүнең берничә вариантын күздә тоткан очракта, рәсми сайт тиешле вариант кысаларында хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алу мөмкинлеген тәэмин итә, шул ук вакытта мөрәҗәгать итүче өчен туры килә торган вариантны билгеләү мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән белешмәләр нигезендә автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин